**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
ЧЕРЕМШАНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**ЧЕРЕМШАНСКОГО**
**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**

Улица М.Титова, дом 7, село Черемшан, 423100

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
**ЧИРМЕШӘН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

М.Титов урамы, 7 йорт, Чирмешән авылы, 423100

тел./факс 8(84396) 2-52-30 email: Cmn.Cmn2@tatar.ru

# ПОСТАНОВЛЕНИЕ
# КАРАР

№ 1 28 гыйнвар 2022 ел

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Чирмешән авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең хакын раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирләү һәм җирләү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2022 елның 27 гыйнварындагы 57 номерлы «2022 елда түләүләрне, пособиеләрне һәм компенсацияләрне индексацияләү коэффициентын раслау турында» карары, «Татарстан Республикасында җирләү һәм җирләү эше турында» Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Чирмешән авыл җирлеге Башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1. 2022 елның 1 февраленнән Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Чирмешән авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен 1 нче кушымта һәм 2 нче кушымта нигезендә 6964,68 сум күләмендә билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.

2. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Чирмешән авыл җирлеге Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Чирмешән авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең хакын раслау турында» 2021 елның 29 гыйнварындагы 3 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга (pravo.tatarstan.ru), махсус мәгълүмат стендларында, шулай ук Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль

районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

ТР Чирмешән муниципаль районы
Чирмешән авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы Н.Г. Гомәрова

1 нче кушымта
Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Чирмешән авыл җирлеге
Башкарма комитеты
карарына
_________ ел № ____

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы
Чирмешән авыл җирлегендә
җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлегенең
бәясе
2022 елның 1 февраленнән

| **Хезмәт күрсәтү атамасы** | **Хезмәт күрсәтү бәясе (сум.)** |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0,00 |
| 2. Җирләү өчен кирәкле табут һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 2534,08 |
| 3. Мәрхүмнең гәүдәсен (җәсәдләрен) зиратка илтү | 1160,80 |
| 4. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 3269,80 |
| **БАРЛЫГЫ** | **6964,68** |

2 нче кушымта
Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Чирмешән авыл җирлеге
Башкарма комитеты
карарына
_________ ел № ____

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы
Чирмешән авыл җирлегендә
җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлегенең
бәясе
2022 елның 1 февраленнән

| **Хезмәт күрсәтү атамасы** | **Хезмәт күрсәтү бәясе (сум.)** |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0,00 |
| 2. Кәфенләү | 263,94 |
| 3. Җирләү өчен кирәкле табут һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 2270,14 |
| 4. Мәрхүмнең гәүдәсен (җәсәдләрен) зиратка илтү | 1160,80 |
| 5. Җирләү (каберләрне казу һәм күмү) | 3269,80 |
| **БАРЛЫГЫ** | **6964,68** |